КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 15 декабрь г.Казань № 999

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторын раслау турында» 2006 ел, 2 май, 220 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 12 февраль, 38 нче; 2007 ел, 13 июль, 297 нче; 2009 ел, 23 март, 161 нче; 2009 ел, 15 июнь, 386 нчы; 2010 ел, 22 февраль, 92 нче; 2010 ел, 9 апрель, 253 нче; 2011 ел, 6 июнь, 452 нче; 2011 ел, 27 июнь, 515 нче; 2011 ел, 8 сентябрь, 750 нче; 2012 ел, 9 февраль, 93 нче; 2012 ел, 29 март, 250 нче; 2012 ел, 8 июнь, 494 нче; 2012 ел, 19 июнь, 524 нче; 2012 ел, 24 декабрь, 1139 нчы; 2013 ел, 22 февраль, 128 нче; 2013 ел, 11 декабрь, 974 нче; 2014 ел, 23 гыйнвар, 30 нчы; 2014 ел, 7 июнь, 388 нче; 2014 ел, 30 август, 630 нчы; 2014 ел, 12 сентябрь, 659 нчы; 2014 ел, 30 октябрь, 823 нче; 2014 ел, 24 ноябрь, 902 нче; 2014 ел, 3 декабрь, 940 нчы; 2015 ел, 2 февраль, 49 нчы; 2016 ел, 15 апрель, 227 нче, 2016 ел, 20 август, 578 нче; 2017 ел, 3 февраль, 58 нче; 2017 ел, 16 март, 148 нче; 2017 ел, 19 июль, 508 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

01.09.01 коды белән функция исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Товарларга (эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә) бәяләрне (тарифларны, өстәмәләрне, арттырмаларны һ.б.) билгеләнгән тәртиптә җайга салу»;

Кодификаторның «Дүртенче» графасына түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | «01.09.01.1 | Электр, җылылык энергиясенә, табигый газга, сыекландырылган газга, су белән тәэмин итү, су агызу өлкәсендәге, каты көнкүреш алдыклары, каты |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә хезмәт күрсәтүләргә бәяләрне (тарифларны) билгеләнгән тәртиптә җайга салу |
| | | | | | | 01.09.01.2 | Җитештерү билгеләнешендәге продукциягә, товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә бәяләрне (тарифларны) билгеләнгән тәртиптә җайга салу, электр, җылылык энергиясенә, табигый газга, сыекландырылган газга, су белән тәэмин итү, су агызу өлкәсендәге, каты көнкүреш алдыклары, каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә хезмәт күрсәтүләргә бәяләрдән (тарифлардан) тыш»; |

01.09.02 коды белән функция исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контролен гамәлгә ашыру;

01.09.02.1, 01.09.02.2, 01.09.02.3 кодлары белән функцияләрне төшереп калдырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2010 ел, 15 июнь, 468 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 20 декабрь, 1087 нче; 2011 ел, 29 июнь, 526 нчы; 2011 ел, 29 июль, 609 нчы; 2011 ел, 7 сентябрь, 747 нче; 2012 ел, 27 апрель, 330 нчы; 2012 ел, 30 июнь, 567 нче; 2012 ел, 30 июль, 645 нче; 2012 ел, 27 октябрь, 908 нче; 2013 ел, 19 март, 186 нчы; 2013 ел, 29 апрель, 296 нчы; 2013 ел, 31 декабрь, 1111 нче; 2014 ел, 20 май, 332 нче; 2014 ел, 26 декабрь, 1039 нчы; 2015 ел, 10 март, 143 нче; 2016 ел, 26 февраль, 118 нче; 2016 ел, 26 декабрь, 996 нчы; 2017 ел, 18 май, 291 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «550,1» саннарын «557,2» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәдә:

3.1 пунктта:

өченче – алтынчы абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«товарларга (эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә) бәяләрне (тарифларны, өстәмәләрне, арттырмаларны һ.б.) билгеләнгән тәртиптә җайга салу» (01.09.01 <*>);

электр, җылылык энергиясенә, табигый газга, сыекландырылган газга, су белән тәэмин итү, су агызу өлкәсендәге, каты көнкүреш алдыклары, каты коммуналь

калдыклар белән эш итү өлкәсендә хезмәт күрсәтүләргә бәяләрне (тарифларны) билгеләнгән тәртиптә җайга салу (01.09.01.1 <*>);

җитештерү билгеләнешендәге продукциягә, товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә бәяләрне (тарифларны) билгеләнгән тәртиптә җайга салу, электр, җылылык энергиясенә, табигый газга, сыекландырылган газга, су белән тәэмин итү, су агызу өлкәсендәге, каты көнкүреш алдыклары, каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә хезмәт күрсәтүләргә бәяләрдән (тарифлардан) тыш (01.09.01.2 <*>);

дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контролен гамәлгә ашыру (01.09.02 <*>).»;

җиденче абзац үз көчен югалткан дип санарга:

3.2 пунктта:

3.2.4 пунктчада:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«электр, җылылык энергиясенә, табигый газга, сыекландырылган газга, су белән тәэмин итү, су агызу өлкәсендәге, каты көнкүреш алдыклары, каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә хезмәт күрсәтүләргә бәяләрне (тарифларны) билгеләнгән тәртиптә җайга салу (01.09.01.1 <*>);»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«калдыклар белән эш итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру белән идарә итү (01.06.09 <*>);»;

3.2.6 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2.6. Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

мәгълүматлаштыру белән идар итү (01.15<*>);

Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системалары үсеше белән идарә итү (дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итүдән тыш) (01.15.02 <*>);»;

3.2.9 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2.9. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен хосусыйлаштыру белән билгеләнгән тәртиптә идарә итү (01.07.03.2);

Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәт белән идарә итү (01.07 <*>);»;

3.2.15 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2.15. Билгеләнгән тәртиптә гражданнарның торакка хокукларын тәэмин итү һәм кулланучыларга сыйфатлы торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе белән (04.01. <*>);»;

түбәндәге эчтәлекле 3.2.16 – 3.2.17 пунктчалар өстәргә:

«3.2.16. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының норма иҗат итү эшчәнлеген координацияләү (шул исәптән Татарстан Республикасы

норматив хокукый актлары проектларының федераль законнарга һәм Татарстан Республикасы законнарына туры килүен тикшерүдә тоту) (02.04.01 <*>);

республика башкарма хакимияте органнарының норматив хокукй актларын дәүләт теркәвенә алу (02.04.03);

3.2.17. Татарстан Республикасының Архив эшләре буенча дәүләт комитеты белән архив эше белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.15.03<*>).»;

4.1 пунктта:

4.1.83 пунктча үз көчен югалткан дип санарга;

түбәндәге эчтәлекле 4.1.114 – 4.1.116 пунктчалар өстәргә:

«4.1.114. Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә чик тарифларны раслый;

4.1.115. Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә эшчәнлекнең җайга салына торган төрләрен гамәлгә ашыручы операторларның каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча җитештерү программаларын раслый;

4.1.116. Татарстан Республикасы территориясендә калдыклар белән эш итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен үткәрүдә катнаша.»;

4.2 пунктта:

4.2.7 – 4.2.9 пунктчаларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2.7. Товарларга (эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә) дәүләт җайга салырга тиеш бәяләрне (тарифлар, өстәмәләр, арттырмаларны) куллану дөреслеге һәм алар зурлыгының нигезле булуы өлешендә дәүләт җайга сала торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыра;

4.2.8. Электр энергетикасы һәм җылылык белән тәэмин итү турында Россия Федерациясе законнары нигезендә җайга салына торганнарга кертелгән инвестицион ресурсларны куллану өлешендә дәүләт җайга сала торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыра;

4.2.9. Газ бүлү системалары буенча газ йөртүне гамәлгә ашыручы табигый монополияләр, электр энергиясеннең күпләп һәм ваклап сату базарлары субъектлары, җылылык белән тәэмин итүче оешмалар, җылылык челтәре оешмалары, коммуналь комплекс оешмалары, каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча операторлар, кайнар су белән тәэмин итүне, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан мәгълүматны ачу стандартларын саклау өлешендә дәүләт җайга сала торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыра;»;

түбәндәге эчтәлекле $4.2.9^1$ пунктча өстәргә:

«$4.2.9^1$. Татарстан Республикасы территориясендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы транспорт компанияләре турында мәгълүматны ачу стандартларын саклауны контрольдә тотуны гамәлгә ашыра;»;

түбәндәге эчтәлекле 6.9 – 6.10 пунктлар өстәргә:

«6.9. Дәүләт комитетын үзгәртеп төзегәндә архив документлары (идарә итү, финанс-хуҗалык, шәхси состав буенча документлар, вакытлы саклау срогы булган документлар) тәртипкә салынып, хокук варисына тапшырыла.

6.10. Дәүләт комитеты бетерелгәндә Татарстан Республикасы архив фонды докментлары, шәхси состав буенча документлар, шулай ук саклау вакытлары

чыкмаган документлар тәртипкә салынып, тиешле дәүләт архивына саклануга тапшырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин